

Ельник районында Ликинье, татарча атамасы икенче ижектә басым ясап Шашка дип атала, бар. Бу – Утешевлар авылы. Шашка авылы, могаен, шулай ук vз тарихында Темниковнын Утешев морзалары белән бәйледер. Бу авылда яшәvчеләрнен барысы да крестьяннар эшләгән, авыл хужалыгы хезмәте белән шогыльләнгәннәр – жир эшкәрткәннәр, терлек асраганнар, каз һәм vрдәк vрчеткәннәр.      Yз вакытында биредә оч татар, оч рус һәм ике мордва авылы кергән зур колхознын бригадасы булган. Ликинье авылында терлекчелек фермасы эшләгән, ә Совет власте азагында бу кечкенә авыл халкы очен клуб ачылган һәм башлангыч мәктәп торгызылган. Хәзерге вакытта биредә даими яшәv очен ун пенсионер гына калган. Акчеево авыл жирлегенә караган Ликинье авылыннан кvп кенә кешеләр Ленинград (хәзерге Санкт-Петербург) шәһәренә кvчеп топләнгәннәр. Әмма, башка авыллардагы кебек vк, жәй айларында биредә туып-vскән кешеләр кайта; кvбесенен әле туган йортлары сакланган. Ата-бабаларнын туган жиренә яшьләр дә килә.

Ликинье авылы бик матур урында– Мокшанын сулъяк ярындагы басу-болыннар, урманнарнар арасында урнашкан. Шул матур табигать кочагында, игенче Рәуф Хусаин улы белән укытучы Рафика Али кызы Утешевлар дvрт балалы (Монир, Монирә, Гелжихан, Наилә) гаиләнен оченчесе буларак Гелжихан туа.

Гелжихан Рәvф кызы Утешева мәктәптә топле белем ала һәм 1975нче елда Зубово-Поляна педагогия училищесын тәмамлый. Кvрше Новое Кадышевода, 18 ел туган Ликиньёсында, аннары Мордовские Пошаты авыллары мәктәпләрендә башлангыч сыйныф укучыларын 40 ел буена укырга-язарга ойрәтә, белем доньясына алып керә. Шул вакыт читтән торып М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институтынын математика факультетын тәмамлый. Укучылары ныклы белем



биргән очен ана рәхмәтлеләр; хормәт итәләр укытучы апаларын. Мәсәлән, 2025 елнын 2 сентябрендә 70-еллык юбилеен Питердә vткәрә Гелжихан Рәvф кызы. Санкт-Петербург

шәһәрендә яшәгән укучысы Али Кәмил улы Утешев апасын юбилее белән котлый һәм бvләк тапшыра.
1978нче елда Гелжихан Рәvф кызы авылнын мактаулы егетләренен берсенә, Кәмил Шекур улына киявгә чыга һәм каен атасы белән 36, кайнанасы белән 38 ел бергә (бvген алар бакыйлыкта), 1993нче елда яна ой салгач та, бергә-бергә дус-тату яшиләр.
Кәмилнен әтисе – Абдул Шекур Мухамеджан улы белән әнисе - Рәбига Айнетдин кызы - авылда хөрмәтле колхозчылар булып иген игкәннәр, оч бала тәрбияләгәннәр, аларны олы тормыш юлына лаеклы кешеләр булып озатканнар. Кәмилләре дә Акчеево топ мәктәбен тәмамлый. Әйтеп китәргә кирәк, тормыш иптәше Гелжихан белән алар классташлар. Кәмил Шекур улы Краснослободск районы авыл хужалыгы техникумында механниклык профессиясен vзләштерерә. Унышлы гына тәмамлап, районындагы «Сельхозтехника» олкәсенә профессиясе буенча хезмәткә урнаша. Гомере буе тырышып хезмәт итә.
Киләчәккә омет итеп яши Утешевлар, оч малайларын – Ильдарны, Дамирны, Маратны тәрбияләп vстерәләр, балаларына белем бирәләр. Элина белән Тимур онyклары оч ай буе әбисе-бабасы янында каникулларда булып Санкт-Петербург шәһәре



ндәге ойләренә китәләр. Әле генә икенче оныклары Тимур беренче сыйныф ишеген ача. Соекле әбиләре дә Питердә була, мәктәпкә оныгын житәкләп алып бара.
Шәхси хужалыкларында мал-туар асрап, кош-корт, яшелчә vстереп гомер итә лаеклы ялдагы Утешевлар. Тан әтәчләре белән бергә торып, тон уртасында гына йокларга ятарга кvнеккән инде авыл кешеләре. Алар атлар, ике сыер, куйлар, vрдәк-тавыклар бихисап кvп асраганнар; бvген дә тайлары, сарыклары, кош-кортлары бар.Бакчаларында яшелчә vстерәләр. Быел, нигәдер, бәрәнгеләре бик ук яхшы булмаган, ә калган яшелчәләре унган. Ингә-ин куеп яшәгән, бер-берсен хормәт иткән, иртән торуга Кәмиле Гелжиханына чәй куйган Утешевлар авыллары очен дә матур эшләрдә катнашалар. Акчеево авыл жирлегенә караган Шашкада яшәv очен газлары, сулары бар, әмма ашка-чәйгә тәмле сулы коесыз авылда яшәv читен. Шуна авыл халкы, чит жирләрдә

яшәvче авылдашлары да ярдәме белән, коеларын янартып тозекләндерәләр. Ельниктан Виктор Давыдкин кольцалар биргән, кем акча, кем хезмәте белән ярдәмләшеп ясаганнар.
Бvген Ельник районындагы кечкенә генә, сvнеп килгән Ликиньё авылында Кәмил Шекур улы белән Гелжихан Рәvф кызы Утешевлар әлегә авылны яшәтеп килvчеләрнен берсе. Бу жирдә аларнын кендек каны тамган, ата-бабалары хезмәт итеп яшәгән. Һәм алар да туган жирләренә, бvген РАЙПО машинасы атнага ике тапкыр гына килсә дә, юллары булмаса да, скорыйнын Ельниктан килvен котсәләр дә, тугърылыклы булып калалар; хезмәт итеп матур гына, татарлыкларын онытмыйча яшиләр. Алар бик тә кунакчыл: һәрвакыт пәрәмәчләре, катламалары, бәлешләре остәлдә. Илләргә - тынычлык, Ватанга - уныш һәм vзләренә, якыннарына, авылдашларына саулык, жан-тән тынычлыгы тели Гелжихан белән Кәмил Утешевлар.

**Наилә НАСЫРОВА**